ГЛАВА АЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2020ел, 3 ноябрь.** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Әлмәт авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Әлмәт авылы гражданнары җыенын Әлмәт авылы мәдәният йорты бинасында 2020 елның 13 ноябренә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, ялгыз өлкән кешеләр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Әлмәт авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) Әлмәт авылының Ленин урамында урнашкан су коесын чистарту һәм төзекләндерү;

2) Триммерлар өчен запас частьләр сатып алу;

3) Әлмәт авылы Ленин урамындагы җәяүлеләр күперен төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу;

4) Әлмәт авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);

5) Әлмәт авылында МТЗ 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары, өстәмә җиһазлар, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү)

6) Әлмәт авылында Ленин урамы, Тукай урамы, Яшьләр урамы, Л. Рәхмәтуллин урамы буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (асфальт өслекләрендәге ярыкларны ясау һәм герметизацияләү өчен материаллар сатып алу);

7) Әлмәт авылында генератор сатып алу;

8) Әлмәт авылында массакүләм чаралар (өлкәннәр көне, инвалидлар көне, 9 Май, яшьләр арасында волейбол, теннис ярышлары) үткәрү өчен бүләкләр алу;

9) Әлмәт торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (ремонт өчен төзелеш материаллары һәм буяулар сатып алу);

ӘЙЕ ЮК?».

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.
4. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Әлмәт авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
5. Әлеге карар ул игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Әлмәт авыл җирлеге башлыгы: Д.Ә. Газизов.